**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 29 гыйнварындагы ПУ-80 номерлы, 2014 елның 10 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2014 елның 5 мартындагы ПУ-244 номерлы, 2014 елның 20 мартындагы ПУ-286 номерлы, 2014 елның 19 апрелендәге ПУ-405 номерлы, 2014 елның 26 апрелендәге ПУ-435 номерлы, 2014 елның 2 июлендәге ПУ-636 номерлы, 2014 елның 12 сентябрендәге ПУ-854 номерлы, 2014 елның 28 ноябрендәге ПУ-1091 номерлы, 2014 елның 5 декабрендәге ПУ-1107 номерлы, 2015 елның 16 мартындагы ПУ-289 номерлы, 2015 елның 18 мартындагы ПУ-294 номерлы, 2015 елның 25 мартындагы ПУ-367 номерлы, 2015 елның 17 июнендәге ПУ-562 номерлы, 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы, 2015 елның 29 июлендәге ПУ-680 номерлы, 2015 елның 10 сентябрендәге ПУ-850 номерлы, 2015 елның 24 сентябрендәге ПУ-892 номерлы һәм 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 14 пунктта «62» һәм «57» саннарын тиешенчә «66» һәм «61» саннарына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:
әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны тиешле тәртиптә финанслауны тәэмин итәргә;
үз актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 ел, 06 апрель
№ ПУ-331